# КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлегенең Биляр-Озеро торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«15» ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2020 елның 15 ноябрендә узган: «Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пункты территориясендә яшәүче, 1 гр инвалидларыннан тыш, 2 төркем инвалидлар (I һәм II дәрәҗә хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән очракта),балачактан инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләр белән тәэмин итү эшләрен үткәрү;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен цистерна сатып алу;

- урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 365 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 237 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 237 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлегенең Биляр-Озеро авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

.

2. Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пункты территориясендә яшәүче, 1 гр инвалидларыннан тыш, 2 төркем инвалидлар (I һәм II дәрәҗә хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән очракта),балачактан инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2021 елда

1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләр белән тәэмин итү эшләрен үткәрү;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен цистерна сатып алу;

- урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биляр-Озеро авыл җирлегенең Биляр-Озеро авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.М.Шәрәфетдинов

Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы: И.М. Шәрәфетдинов